**СОВЕТ ПЕСЧАНО-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422625 с. Песчаные Ковали,
ул. Октябрьская, д.9 а
тел: (факс ) 8 84378 4-56-47
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОМЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422625 Комлы Ковал авылы,
Октябрьск урамы, 9 а нчы йорт,
тел: (факс ) 8 84378 4-56-47
E-mail:Pkov.La@tatar.ru

---

**2024 елның 06 марты** **285 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022елның 14 декабрендәге 179 номерлы Комлы Ковал авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (23.08.2023ел, 27.11.2023 ел карарларындагы үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясе бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге советы карар кабул итте**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау турында»2022 елның 14 декабрендәге 179 номерлы Комлы Ковал авыл җирлеге карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә;

1) **7 статьяның 6 өлеше** түбәндәге эчтәлектәге пунктча белән тулыландырырга:

Бюджет акчаларының баш идарәчесе:
"Электрон бюджет" иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында, капитал салуларын финанс белән тәэмин итү (финанслаштыру) чыганагы федераль бюджет акчалары булган, капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез милек объектлары турында белешмәләр формалаштыра;

2) **27 статьяның 7 өлешендәге 5 абзацтагы сүзләр**
"Федераль адреслы инвестиция программасында каралган" төшереп калдырырга, "Федераль адреслы инвестиция программасына кертелгән чараларны (зурайтылган инвестиция проектларын) детальләштерүгә бәйле рәвештә"сүзләрен " капиталь төзелеш объектлары, күчемсез мөлкәт объектлары реестрына кертелгән белешмәләрне детальләштерүгә бәйле рәвештә" сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.

веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Н.С. Гыйлаҗетдинова**